**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА
СТЕПНООЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БИКҮЛЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 06» октябрь 2023 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 18 октябрендә 14 сәгать 00 минутта М. Горький урамы буенча 13нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында М. Горький урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә

2. 2023 елның 18 октябрендә 15 сәгать 00 минутта Совет урамы буенча 14нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында Совет урамы буенча, Клуб урамы буенча, Илюткино авылындагы Җиңү урамы буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Илюткино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш 2024 елда 2500 сум күләмендә үзара

салым кертү белән һәм җыелган  акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (грунт катыш щебеньнан юл өслеген күтәрү, вак таш салу);
- Илюткино авылында буа территориясен төзекләндерү;
- Су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү;
- Парк зонасын төзекләндерү;
- Территорияне төзекләндерү, (агачларны кисү);
- Күперне ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Илюткино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова